**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы хәрби хезмәткә чакыру комиссиясе составына һәм резерв составына үзгәрешләр кертү турында

Аерым затларның башка эшкә күчүе белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы хәрби хезмәткә чакыру комиссиясе турында» 2005 елның 14 мартындагы ПУ-86 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2005 елның 16 маендагы ПУ-200 номерлы, 2005 елның 22 октябрендәге ПУ-406 номерлы, 2006 елның 28 апрелендәге ПУ-162 номерлы, 2007 елның 30 мартындагы ПУ-163 номерлы, 2007 елның 12 октябрендәге ПУ-542 номерлы, 2008 елның 7 мартындагы ПУ-106 номерлы, 2008 елның 29 сентябрендәге ПУ-461 номерлы, 2008 елның 17 декабрендәге ПУ-659 номерлы, 2009 елның 25 мартындагы ПУ-171 номерлы, 2009 елның 3 июнендәге ПУ-317 номерлы, 2009 елның 1 октябрендәге ПУ-500а номерлы, 2010 елның 30 мартындагы ПУ-181 номерлы, 2010 елның 3 июнендәге ПУ-364 номерлы, 2010 елның 7 октябрендәге ПУ-666 номерлы, 2010 елның 21 декабрендәге ПУ-834 номерлы, 2011 елның 26 мартындагы ПУ-155 номерлы, 2011 елның 10 маендагы ПУ-257 номерлы, 2011 елның 30 сентябрендәге ПУ-604 номерлы, 2011 елның 21 октябрендәге ПУ-661 номерлы, 2011 елның 29 декабрендәге ПУ-890 номерлы, 2012 елның 24 мартындагы ПУ-217 номерлы, 2012 елның 29 июнендәге ПУ-520 номерлы, 2012 елның 27 сентябрендәге ПУ-785 номерлы, 2013 елның 25 февралендәге ПУ-157 номерлы, 2013 елның 26 сентябрендәге ПУ-944 номерлы, 2014 елның 20 февралендәге ПУ-183 номерлы, 2014 елның 27 мартындагы ПУ-313 номерлы, 2014 елның 29 сентябрендәге ПУ-933 номерлы һәм 2014 елның 18 декабрендәге ПУ-1145 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы хәрби хезмәткә чакыру комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Татарстан Республикасы хәрби хезмәткә чакыру комиссиясе составыннан А.А. Газизованы, Р.М. Сибгатуллинаны чыгарырга;

б) Татарстан Республикасы хәрби хезмәткә чакыру комиссиясе составына кертергә:

Вәкилова Инесса Рөстәм кызын – Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты бүлеге (гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү һәм чакыру) хәрби-табиблык комиссиясе стоматологын, табиб-белгечен;

Гыйлаҗев Азат Әскәр улын – Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе табиб-отоларингологын;

Гыйлалов Марат Наил улын – Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты бүлеге (гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү һәм чакыру) хәрби-табиблык комиссиясе отоларингологы, табиб-белгечен;

в) Татарстан Республикасы хәрби хезмәткә чакыру комиссиясенең резерв составыннан И.Р. Вәкилованы, Ю.И. Низаметдинованы, С.Ю. Махотинаны чыгарырга;

б) Татарстан Республикасы хәрби хезмәткә чакыру комиссиясенең резерв составына кертергә:

Сәгыйрова Алинә Габделхак кызын – Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика стоматология поликлиникасы табиб стоматолог-терапевтын;

Галәвиева Лилия Мөҗип кызын – Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика стоматология поликлиникасы табиб стоматолог-терапевтын;

Миңнемуллина Гөлсәрия Хөсәен кызын – Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник тире-венерология диспансеры табиб-дерматовенерологын.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы** **Р.Н. Миңнеханов**

Татарстан Республикасы Президенты Аппараты * Аппарат Президента Республики Татарстан
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2015 ел, 25 март
№ ПУ-366